КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 29 гыйнвар г.Казань № 48

«Умартачылык идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесе исемен алыштыру турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының «Умартачылык идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесе исемен «Татарстан Республикасының Аквакультура һәм умартачылык идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – учреждение) дип алыштыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Учреждение эшчәнлегенең төп максатлары балык һәм умарта кортларының продуктивлыгын арттыруны, балык һәм умарта корты төрләренең сыйфатларын яхшыртуны тәэмин итү; балык һәм умарта кортларының санын арттыру һәм аларны саклап калу; балык һәм умарта кортларын үрчетүне һәм үстерүне, умартачылык һәм балык үрчетү эше продуктларын арттыру дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына:

60 көн эчендә учреждение Уставына билгеләнгән тәртиптә үзгәрешләр кертергә;

учреждение өчен дәүләт йөкләмәсенә үзгәрешләр кертергә.

4. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә, Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белән берлектә, учреждение уставына кертелгән үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алганнан соң 30 көн эчендә аны бу карарның 1 нче пунктына туры китерү өлешендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 елга Татарстан Республикасының кайбер дәүләт учреждениеләре норматив чыгымнарын раслау турында» 2017 ел, 18 сентябрь, 700 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

5. Учреждение тарафыннан дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карары белән билгеләнгән тәртиптә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында әлеге максатларга күздә тотылган акча чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин